**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1059

г. Казань

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын күтәрү, алардан һәркем файдалана алуны тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында төп белем бирү программалары буенча һәркем алырлык түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2011 ел, 18 май, 396 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 30 декабрь, 1059 нчы
карары белән расланды

# Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты

## 1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәтеннән (алга таба – дәүләт хезмәте) файдаланучылар булып ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар (алга таба – балалар) тора.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезләре

Дәүләт хезмәте түбәндәге закон актлары, норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

Бала хокуклары турында конвенция (1989 елның 20 ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе тарафыннан хупланды);

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

«Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 ел, 21 декабрь, ФЗ-159 нчы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 ел, 24 июль, ФЗ-124 нче Федераль закон;

«Балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 ел, 24 июнь, ФЗ-120 нче Федераль закон;

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 ел, 24 апрель, ФЗ-48 нче Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 ел, 22 июль, ФЗ-123 нче Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон;

«Куллanучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарга мөнәсәбәтле опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 ел, 18 май, 423 нче карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан

мәхрүм калган балалар оешмаларында булган балаларны даими Россия Федерациясе территориясендә яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү турында» 2009 ел, 19 май, 432 нче карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары эшчәнлеге турында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны анда урнаштыру хакында» 2014 ел, 24 май, 481нче карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары төзелешенә, аларны карап тоту һәм эш режимын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.4.3259-15 раслау турында» 2015 ел, 9 февраль, 8 нче карары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы;

«Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның хәлен яхшырту буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2003 ел, 16 май, 266 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йорты (алга таба – балалар йорты) уставы;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка актлар.

## 3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Документ исеме | Документларны бирүне гамәлгә ашыручы оешма исеме | Документның аны биргән көннән гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Баланы балалар йортына күзәтчелеккә алу турында опека һәм попечительлек органы акты | опека һәм попечительлек органнары | вакыты чикләнмәгән |
| 2. | Карамагында балалар йорты булган гамәлгә куючы яки ведомство биргән балалар йортына юллама | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 10 эш көне |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Туу турында таныклык (төп нөсхә), булмаганда – баланың яшен раслый торган медицина экспертизасы бәяләмәсе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданнар хәле актларын язу идарәсе территориаль органнары | вакыты чикләнмәгән |
| 4. | Баланың сәламәтлеге торышы турында медицина документлары | баланың яшәү урыны буенча медицина оешмасы | балигъ булганчы |
| 5. | Белем турында документлар (мәктәп яшендәге балалар өчен) | белем бирү оешмасы | вакыты чикләнмәгән |
| 6. | Баланың яшәү шартларын тикшерү акты | опека һәм попечительлек органнары | ел дәвамында |
| 7. | Ата-аналары яки законлы вәкилләре турында мәгълүматлар (ата-аналары үлеме турында таныклыкның, суд хөкеме яки карарының төп нөсхәләре, ата-аналарының авыруы яки аларны эзләү хакында белешмә һәм ата-аналары булмавын яки аларның үз балаларын тәрбияли алмауны раслый торган башка документлар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданнар хәле актларын язу идарәсе территориаль органнары, суд органнары, опека һәм попечительлек органнары | вакыты чикләнмәгән |
| 8. | Абый-энеләре, апа-сеңелләре һәм бүтән якын туганнарының булуы һәм яшәү урыны турында белешмә (булганда) | опека һәм попечительлек органнары | ел дәвамында |
| 9. | Ата-анасы үлеменнән соң калган мөлкәт исемлеге, аларның сакланышы өчен җавап биргән затлар хакында мәгълүматлар (булганда) | опека һәм попечительлек органнары | вакыты чикләнмәгән |
| 10. | Пенсия алучы баланың пенсия кенәгәсе, алиментлар түләттерү турында суд карары күчермәсе, кыйммәтле кәгазьләр (аларны балага ата-аналар яки законлы вәкилләр алганда) | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекләре | балигъ булганчы |
| 11. | Территориаль психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен) | шәһәр, республика психологик-медицина-педагогик комиссиясе | вакыты чикләнмәгән |

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибенә һәм шартларына таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге максатларда күрсәтелә:

шәхеснең акыл, эмоциональ һәм физик үсешенә ярдәм итә торган өй шартларына охшаш уңай шарлар тудыру;

балаларны социаль яклауны, медицина-психологик-педагогик тернәкләндерүне һәм аларның социаль адаптациясен тәэмин итү;

балаларның сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны тәэмин итү;

балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау.

4.2. Балалар аларның сәламәтлек торышына һәм ихтыяҗларына туры килә торган аларны карап тоту, тәрбияләү һәм белем бирү өчен барлык кирәкле шартлар булдырылган балалар йортына күзәтчелеккә алына.

4.3. Балалар балалар йортына күзәтчелеккә балаларны билгеләгән көннән соң бер ай эчендә опека һәм попечительлек органы кабул итә торган баланы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортына күзәтчелеккә алу турында опека һәм попечительлек органы акты нигезендә алына.

4.4. Балалар йорты әлеге Стандартның 4.3 нче пунктында күрсәтелгән акт чыккан көннән соң бер ай эчендә балалар йортына күзәтчелеккә алына торган баланы Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган медицина тикшерүенә җибәрүне тәэмин итә. Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы балага медицина тикшерүе үткәрү нәтиҗәләре буенча, опека һәм попечительлек органына бирелә торган медицина тикшерүе нәтиҗәләрен теркәп, баланың сәламәтлеге торышы турында бәяләмә бирелә.

4.5. Балалар йортына сәламәтлегенең мөмкинлекләре чикләнгән баланы алган очракта, балалар йорты аны Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештереп билгеләгән тәртиптә үткәрелә торган комплекслы психологик-медицина-педагогик тикшерүгә җибәрүне тәэмин итә, һәм аның нәтиҗәләре буенча территориаль психологик-медицина-педагогик тикшерү бәяләмәсе бирелә.

4.6. Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шул исәптән гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукын тәмин итү һәм яклау максатларында, балалар йорты тарафыннан баланың үсеше һәм тормышта урнашуы буенча шәхси план төзелә, һәм ул опека һәм попечительлек органының тиешле акты белән раслана һәм кимендә ярты елга бер тапкыр карап тикшерелә.

4.7. Балалар йортына түбәндәгеләр кабул ителә:

ятим балалар;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар.

Балалар йортына кабул итү көн саен 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр гамәлгә ашырыла.

4.8. Россия Федерациясе Гаилә кодексының 155.1 статьясындагы 2 нче пункт нигезендә ата-аналары, уллыкка (кызлыкка) алучылары яисә опекуннары (попечительләре) (алга таба – законлы вәкилләре) балаларына мөнәсәбәтле үз вазыйфаларын башкара алмаган балалар законлы вәкилләренең гаризасы буенча, шулай ук 10 яшькә җиткән баланың фикерен исәпкә алып, вакытлыча балалар йортына

урнаштырыла ала.

4.9. Бер гаилә әгъзалары булган яки туганлык мөнәсәбәтләрендә торган балалар, шул исәптән әлеге Стандартның 4.8 нче пунктында күрсәтелгән балалар, бер үк балалар йортына җибәрелә һәм бер төркемдә урнаштырыла, балаларның мәнфәгатьләренә каршы килгән очраклардан тыш.

4.10. Баланың гадәти социаль мохитен, туганлык һәм дуслык мөнәсәбәтләрен саклау, бала йөргән мәгариф оешмасында белем алуын дәвам иттерү максатларында, балалар аларның яшәү яки тору урынына территориаль яктан иң якын урнашкан балалар йортына күзәтчелеккә алына, гадәти социаль мохит балаларның тәртибенә тискәре йогынты ясаган, балаларның социаль булмаган тәртибенә һәм (яки) балалар йортыннан рөхсәтсез китүенә китергән очраклардан тыш.

4.11. Балалар тумыштан һәм 3 яше тулганчы әлеге яшь төркемендәге балаларны тәрбияләү һәм аларның яшәве өчен каралган шартлар булдырылган балалар йортына күзәтчелеккә алына.

4.12. Балалар йорты Россия Федерациясе законнары таләпләренә җавап биргән балаларның яшәү шартларын тәэмин итә.

4.13. Балалар йорты тарафыннан балаларны өстәмә гомуми үстерүче программалар буенча укытуны оештыру, шул исәптән балаларның кызыксынулары буенча башка оешмаларда эшләп килгән клубларга, секцияләргә, түгәрәкләргә, студияләргә һәм берләшмәләргә баруы, шулай ук аларның яшен һәм сәламәтлеге торышын, физик һәм психик үсешен исәпкә алып, конкурсларда, олимпиадаларда, күргәзмәләрдә, смотрларда һәм балалар өчен массакүләм чараларда катнашуы тәэмин ителә, шул исәптән әлеге чараларда балалар йорты хезмәткәрләре һәм ирекләләр (волонтерлар) катнашуын тәэмин итү юлы белән.

4.14. Балаларның торуы фатир төре буенча төзелгән яшәү урыннарында урнаштырыла торган тәрбияләү төркемнәрендә гаилә тәрбиясе принциплары нигезендә оештырыла.

4.15. Тәрбияләү төркемнәре башлыча төрле яшьтәге һәм төрле сәламәтлек торышы булган балаларның, беренче чиратта, бертуган һәм әтисе яки әнисе бер булган абый-энеләр һәм апа-сеңелләрнең, бер гаилә әгъзалары булган балаларның яки элек бер гаиләдә тәрбияләнгән туганлык мөнәсәбәтләрендә торган балаларның төркемдә бергә яшәве һәм торуы принцибы буенча формалаштырыла. 4 яшьтән өлкән төрле җенестәге балалар төркемдә көндезге вакытта бергә яши һәм тора алалар.

4.16. Тәрбияләү төркемендәге балалар саны – 8 кешедән, ә 4 яшькәчә балалар 6 кешедән артмаска тиеш.

4.17. Балаларны бер тәрбияләү төркеменнән икенчесенә күчерү рөхсәт ителми, баланың мәнфәгатьләренә каршы килгән очраклардан тыш.

4.18. Балаларны тәрбияләүне оештыру аларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең, шулай ук иҗтимагый файдалы хезмәтнең һәм ялның рациональ кушылмасын тәэмин иткән көн тәртибе балаларның тәүлек буе балалар йортында булуын исәпкә алып төзелә һәм балаларның массакүләм ял итү чараларында (шәхси вакытны кертеп) катнашуын, балаларның яшен һәм кызыксынуларын игътибарга алып, ялны үткәрү формасын

мөстәкыйль сайлау мөмкинлеген бирүне исәпкә ала.

4.19. Каникуллар чорында балаларның ялы һәм аларны савыктыру балалар йорты җитәкчесе раслый торган балаларның акыл, эмоциональ, рухи, әхлакый һәм физик үсешенә юнәлдерелгән танып белү, мәдәни-күңел ачу һәм физкультура-савыктыру чараларын үз эченә алган план нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә таләпләр

5.1. Биналарда функциональ зоналар һәм урыннар күздә тотыла, шул исәптән:

балалар һәм тәрбиячеләр тору өчен, шул исәптән:

ял итү, уйнау, уку өчен;

азык-төлек продуктларын һәм азык-төлек чималын саклау, ризык әзерләү һәм ашау өчен;

мөстәкыйль йөрү чараларын, техник тернәкләндерү чараларын, спорт инвентарен саклау өчен;

медицина хезмәте күрсәтү өчен;

тернәкләндерү чаралары үткәрү өчен;

административ-хуҗалык билгеләнешендәге;

санитария-көнкүреш бүлмәләре.

5.2. Аларда балалар тору өчен каралган бүлмәләрне урнаштыру өчен цоколь катларын һәм подвалдагы биналарны файдалану рөхсәт ителми.

5.3. Балалар йортында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар тору шартларын булдыру өчен төзелеш һәм реконструкция вакытында биналарда һәм бүлмәләрдә балаларның йөри алуын тәэмин итә торган уңайлы (киртәләрсез) мохит төзү буенча чаралар күздә тотыла.

5.4. Тәрбияләү төркемнәре урыннары үз эченә түбәндәгеләрне ала:

торак бүлмәләр (йокы бүлмәләре);

ял итү һәм уйнау өчен бүлмә (кунак бүлмәсе);

укулар (дәрес хәзерләү) өчен бүлмә;

аш һәм (яки) ризык әзерләү бүлмәсе;

санитария-көнкүреш бүлмәләре (санитария челтәрләре, душ яки ванна бүлмәсе);

тәрбияче бүлмәсе; чишенү бүлмәсе (өйалды).

5.5. Мәктәп яшендәге балаларга кызлар һәм малайлар өчен аерым торак бүлмәләр (йокы бүлмәләре) күздә тотыла. Бер торак бүлмәдә (йокы бүлмәсендә) 4 баладан артык яшәү рөхсәт ителми.

Санитария челтәрләре һәм душ (ванна) бүлмәләре саны бер тәрбияләү төркеменә кимендә икене тәшкил итәргә тиеш.

5.6. Торак бүлмәләр (йокы бүлмәләре) балаларның буй-яшь үзенчәлекләре нигезендә стационар караватлар, балаларның шәхси әйберләрен саклау өчен шкафлар, тумбочкалар белән җиһазландырыла. Өстәлләр һәм урындыклар кую рөхсәт ителә. Шәхси әйберләрне саклау өчен шкафлар тәрбияләү төркеменең башка бүлмәләрендә куела ала.

Җәелә торган һәм трансформер (тартып чыгарыла торган, тәгәрәтеп чыгарыла торган) караватлар файдалану рөхсәт ителми.

5.7. Ял итү һәм уйнау өчен бүлмә (кунак бүлмәсе) уеннарны һәм уенчыкларны, үстерә, укыта-өйрәтә торган җайланмаларны һәм инвентарьне, нәшрият продукциясен саклау өчен шкафлар, тумбалар, стеллажлар, өстәлләр һәм урындыклар, йомшак җиһазлар (диваннар, кәнәфиләр) һәм башка җиһазлар белән җиһазландырыла.

5.8. Балалар йортында балаларның сәламәтлегенә зыян китермәгән һәм куркынычсызлыкны раслый торган документлары булган җиһазлар һәм уенчыклар файдаланыла.

5.9. Укулар (дәрес хәзерләү) өчен бүлмә балаларның буй-яшь үзенчәлекләре нигезендә канцелярия шкафлары, өстәлләр һәм урындыклар белән җиһазландырыла.

5.10. Балалар җиһазы, үстерә, укыта-өйрәтә торган, уен, спорт җиһазлары һәм инвентаре, нәшрият продукциясе, техник һәм аудиовизуаль чаралар санитария-эпидемиология таләпләренә туры килергә, балаларның сәламәтлеге өчен зарарсыз булырга һәм педагогик процессны һәм дәвалау-тергезү чараларын оештыру үзенчәлекләрен исәпкә алырга, шулай ук балаларның буена һәм яшенә туры килергә тиеш.

5.11. Балаларның туклануы аш һәм (яки) ризык әзерләү бүлмәсендә яки балаларның ял итү һәм уйнау бүлмәсендә оештырыла. Утыра торган урыннар саны барлык балаларның берьюлы туклануын тәэмин итәргә тиеш.

## 6. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең куркынычсызлыгына карата таләпләр

6.1. Балалар йортының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе була.

6.2. Балалар йортының уставы Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры килә.

6.3. Балалар йорты территориясен карап тоту тиешле төрдәге мәгариф оешмалары биналары янындагы территорияләр өчен санитария-эпидемиология нормалары һәм кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләргә туры килә.

Территория төзекләндерелгән һәм яшелләндерелгән булырга тиеш.

Балалар йорты территориясе балаларның буй-яшь үзенчәлекләре нигезендә уен һәм спорт җиһазлары белән тәмин ителә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен уен мәйданчыкларында комлыклар куела.

Территориядә балалар йортына функциональ бәйле булмаган төзелмәләр һәм корылмалар булуы рөхсәт ителми.

Балалар йорты территориясе көн саен җыештырыла.

Кышкы вакытта территория кирәк булган саен кардан чистартыла, территориягә ком сибәргә рөхсәт ителә. Химик реагентлардан файдалану рөхсәт ителми.

Балалар йорты табигый һәм ясалма яктырту чыганаклары (бүлмәләрдә яктырту дәрәҗәсе санитария кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш), ягып җылыту һәм җилләтү системалары белән (ягып җылыту, һаваны

җилләтү һәм/яки сафландыру системалары бүлмәләр микроклиматының һәм һавасының нормалаштырылган параметрларын тәэмин итәргә тиеш) җиһазландырылган була.

6.4. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә файдаланыла торган предметлар һәм җиһазлар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән санитария таләпләренә җавап бирә. Алда әйтелгән бүлмәләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү яки балаларның тору шартларын тәэмин итү процессына бәйле булмаган җиһазлар булмаска тиеш.

Балалар йорты кичектергесез полиция чакырту төймәсе белән җиһазландырылган һәм тәүлек буе саклау белән тәэмин ителгән була.

Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта, балалар йорты персоналы барлык балаларның эвакуациясен һәм коткаруны тәэмин итә. Гадәттән тыш хәл барлыкка килгән мизгелдән һәм аны тулысынча бетергәнче яки балаларны эвакуацияләгәнче балаларны караусыз калдыру рөхсәт ителми.

6.5. Балалар йорты түбәндәгеләр белән җиһазландырылган була:

автомат янгын сигнализациясе;

янгын турында хәбәр итү системасы;

кирәкле янгын сүндерү чаралары;

үз-үзеңне саклау чаралары;

эвакуацияне оештыру өчен кирәкле чаралар.

6.6. Балалар йортында:

янгын очрагында кешеләрне эвакуацияләү планнары (схемалары) күренеп торган урыннарда эленгән була;

кешеләрне куркынычсыз һәм тиз рәвештә эвакуацияләүне тәэмин итү буенча персоналның эш-гамәлләрен билгели торган инструкция була;

кимендә ярты елга бер тапкыр балалар йортының эвакуациягә җәлеп ителгән барлык хезмәткәрләренә гамәли күнегүләр үткәрелә.

## 7. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар өчен дәүләт хезмәтеннән файдалана алуны тәэмин иткән таләпләр

7.1. Балалар йорты Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан була.

7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, балалар йортының эш режимын исәпкә алып, ел буе гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү урыны, вакыты һәм аннан файдаланучыларны кабул итү турында бөтен мәгълүмат балалар йортының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында була.

7.3. Балалар йортының эш режимы балалар йорты уставы һәм балалар йортының башка җирле актлары белән регламентлаштырыла.

## 8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

8.1. Балалар йорты штат расписаниесе һәм балалар тупланган төркемнәр саны

нигезендә квалификацияле белгечләр белән комплектланган булырга тиеш. Балалар йорты персоналын комплектлау тәртибе аның уставы белән регламентлаштырыла.

8.2. Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукы урта һөнәри яки югары белеме булган һәм квалификация белешмәлекләрендә күрсәтелгән квалификация таләпләренә һәм (яки) һөнәри стандартларга җавап биргән затларда була.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә балалар йортындагы педагогик эшчәнлеккә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары нигезендә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгән;

шәхеснең гомере һәм сәламәтлегенә, иреге, намусы һәм горурлыгына каршы (стационар шартларында психиатрия ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз госпитальләштерүдән һәм яла ягудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, конституцион төзелеш нигезләренә һәм дәүләт иминлегенә, кешелек тынычлыгы һәм куркынычсызлыгына каршы, әлеге пунктның бишенче абзацында күздә тотылган очраклардан тыш, шулай ук җәмәгатьчелек куркынычсызлыгына каршы кылган җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар булган (аклау сәбәпле аларга карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), хөкемгә тартылган яки тартылган булган;

башка аңлы рәвештә эшләнгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр, әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелмәгән җинаятьләр өчен суд хөкеме гамәлдән чыгарылмаган яки тәмамланмаган булган;

федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы раслый торган исемлектә каралган авырулары булган.

8.3. Балалар йортының педагогик хезмәткәрләре кимендә өч елга бер тапкыр өстәмә педагогик эшчәнлек профиле буенча һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программаларын һәм яңадан һөнәри әзерләү программаларын) гамәлгә ашыру юлы белән мәгариф оешмаларында өстәмә һөнәри белем ала.

8.4. Тәрбия бирү процессы педагогика өлкәсендәге белгечләр, шулай ук балалар йорты эшчәнлегенең профиле буенча тиешле өстәмә белем алган тәрбиячеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.5. Балалар йортында белем бирү процессын психологик тәэмин итүне балалар йорты штатына керә торган психолог гамәлгә ашыра.

8.6. Белгечләр законнарда билгеләнгән тәртиптә аттестация үтәләр һәм квалификация күтәрәләр.

8.7. Белгечләр аларның бурычларын, хокукларын һәм җаваплылыгын билгели торган вазыйфаи инструкцияләр нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша.

8.8. Белгечләр уставны, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәргә, вазыйфаи инструкцияләр нигезендә функциональ вазыйфаларын сыйфатлы итеп башкарырга, һөнәри этиканы сакларга тиеш.

8.9. Тиешле квалификация һәм профессиональлек белән беррәттән, балалар йортының бөтен белгечләре югары әхлакый һәм әхлакый-этик сыйфатларга,

җаваплылыкка ия булырга һәм эш вакытында кешелеклелек, гаделлек, объективлык һәм шәфкатьлелек принципларына таянып эш итәргә тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә балалар йорты хезмәткәрләре, балаларның физик һәм психик хәлен исәпкә алып, аларга карата мөмкин кадәр сак, әдәпле, игътибарлы, түземле, алдын-артын уйлап эш итүчән, сабыр булырга тиеш.

## 9. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итүгә карата таләпләр

9.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мәгълүмат (алга таба – мәгълүмат) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы таләпләре нигезендә урнаштырыла.

9.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар өчен мәгълүмат балалар йорты тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, балалар йортының мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша балалар йортының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

9.3. Балалар йорты тарафыннан гражданнар игътибарына мәгълүмат җиткерү ысулы, вакытлары һәм тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.

## 10. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге Стандартның 3 бүлеге буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән документларның тулы булмаган исемлеге тора.

# 11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре тасирламасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе түбәндәге дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты индикаторлары белән бәяләнә:

| Сыйфатны бәяләү күрсәткече исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Үлчәү коэффи-циенты | Иң чик мәгънә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе органнары тикшерүләр үткәргәндә ачыкланган хисап елында санитария законнарын бозулар саны | берәмлек | контроль-күзәтчелек органнары күрсәтмәләрендә теркәлгән бозулар саны | 8 | 0 |
| 2. Хезмәтләрнең сыйфаты һәм уңайлылыгыннан канәгать булган дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар өлеше | процент | $\frac{\frac{Ок + Од}{2}}{Ообщ} \times 100\%$,<br>монда:<br>Ок – хезмәтләрнең сыйфатыннан канәгать булган сораштыру үткәрелгәннәр саны;<br>Од – хезмәтләрнең уңайлылыгыннан канәгать булган сораштыру үткәрелгәннәр саны;<br>Ообщ – сораштыру үткәрелгәннәрнең гомуми саны | 9 | 905 |
| 3. Тереклек эшчәнлеге иминлеген бозу очраклары саны | берәмлек | хезмәтне саклау таләпләрен бозганга, оешма, мәктәп яны территориясе матди базасының канәгатьләндермәслек хәленә бәйле белем бирү процессында катнашучыларның җәрәхәтләнү очраклары исәпкә алына | 6 | 0 |
| 4. Штат хезмәткәрләре белән комплектланган булу | процент | $\frac{Ч_{ф}}{Ч_{шр}} \times 100\%$,<br>монда: | 6 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Чф – оешма хезмәткәрләренең факттагы саны;<br>Чшр – оешма хезмәткәрләренең штат расписаниесендә каралган саны | | |
| 5. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Ж_o}{Ж} \times 100\%$,<br>монда:<br>$Ж_o$ – дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның хисап чорында кертелгән нигезле шикаятьләре саны;<br>Ж – дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның хисап чорында кертелгән шикаятьләренең гомуми саны | 9 | 0 |
| 6. Укучылар арасында хокук бозулар һәм җинаятьләр саны | берәмлек | хокук бозулар саны | 7 | 0 |

## 12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгәнгә шикаятьләрне бирү, теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозганга, Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгәнгә шикаять (алга таба – шикаять) балалар йортына язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә. Балалар йорты җитәкчесе кабул иткән карарга шикаять югары органга (балалар йортын гамәлгә куючы) бирелә.

12.2. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, балалар йортының рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук дәүләт хезмәтеннән файдаланучыны шәхсән кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

12.3. Шикаять бирелгән көнне мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә, ә балалар йортының, балалар йорты вазыйфаи затының дәүләт хезмәтеннән файдаланучыдан документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яисә мондый төзәтүләр өчен билгеләнгән вакытны бозганга шикаять белдергән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан карап тикшерелергә тиеш.

12.4. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча балалар йорты дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, хезмәттән файдаланучыга шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре хакында язма рәвештә һәм хезмәтләрдән файдаланучы теләге буенча – электрон рәвештә мотивлашкан җавап җибәрә.

12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелә ала.

## 13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе

13.1. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиядә каралган шартларны балалар йорты тарафыннан үтәүне тикшерүдә тоту лицензияне биргән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

13.2. Дәүләт хакимияте органары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 14. Дәүләт хезмәтен түләүле яки түләүсез күрсәтү турында мәгълүмат

Дәүләт хезмәте тулысынча дәүләт тәэмин итүе нигезендә түләүсез күрсәтелә.

---